**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2022 елның 20 декабре 466№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 20 июнендәге «Контракт хезмәте, контракт хезмәтенең даими составы һәм контракт идарәчесенең типовой вазыйфаи инструкциясе турында регламентны раслау хакында» 241 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2022 елның 16 апрелендәге “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 104-ФЗ номерлы Федераль закон, 2021 елның 2 июлендәге “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 360-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1.Контракт хезмәте, контракт хезмәтенең даими составы һәм контракт идарәчесенең типовой вазыйфаи инструкциясе турындагы регламентка (11.03.2019г № 105, 29.10.2021 № 467 яңа ред.) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктның 7 абзацында "сатып алулар турындагы документлар" сүзләреннән соң "(әлеге Федераль законда сатып алу турындагы документларда каралган очракта)";

1.3 пунктның 8 абзацында "җиткерүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) ябык ысуллар белән билгеләүдә катнашырга" сүзләрен төшереп калдырырга;

14 пунктның 5 пунктчасының 2 нче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

Регламентның 2нче кушымтасын әлеге карарның 1нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

17 пунктта түбәндәге эчтәлекле 4) пунктча өстәргә:

"4) сатып алуларны гамәлгә ашырганда мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу чараларын 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы көрәш турында" 273-ФЗ номерлы Федераль закон, шул исәптән заказчыга әлеге Федераль законның 34 статьясы 23 өлеше нигезендә бирелгән мәгълүматны исәпкә алып, кабул итә.".

Регламентның 3 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:

"21.Контракт хезмәте хезмәткәрләре сатып алуларны гамәлгә ашырганда мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу чараларын 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы көрәш турында" 273-ФЗ номерлы Федераль закон, шул исәптән заказчыга әлеге Федераль законның 34 статьясы 23 өлеше нигезендә бирелгән мәгълүматны исәпкә алып, кабул итә.".

Регламентның 3 нче кушымтасы 2 пунктында түбәндәге эчтәлекле 2.18 пунктчасын өстәргә:

"2.18 Сатып алуларны гамәлгә ашырганда мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу чараларын 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы көрәш турында" 273-ФЗ номерлы Федераль закон, шул исәптән заказчыга әлеге Федераль законның 34 статьясы 23 өлеше нигезендә бирелгән мәгълүматны исәпкә алып, кабул итә.".

Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталы"нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендәге Әлки муниципаль районының рәсми сайтында http://alkeevskiy.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Җитәкче: Р.Х.Морадымов

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитетының 2022
елның 20 декабрендәге 466
номерлы карарына1 нче
кушымта

# Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының аерым структур бүлекчәсен төземичә контракт хезмәте функцияләрен башкаручы хезмәткәрләрнең даими составы

| | |
|---|---|
| Контракт хезмәте җитәкчесе | |
| Контракт хезмәте җитәкчесе урынбасары | |
| Әлки муниципаль районы Советының юридик бүлек начальнигы | |
| Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы | |
| "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы" МКУ рәисе | |
| "Әлки районы мәдәният бүлеге" МКУ начальнигы | |
| Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге начальнигы | |
| Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге начальнигы | |
| Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге начальнигы | |
| Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге баш белгече | |
| "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе" МКУ җитәкчесе | |